Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Клубная, Озерная урамнарында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

14 ноябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы нигезендә, 2025 елның 14 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта узган «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Клубная, Озерная урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- тротуарларны төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту буенча эшләр башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 104 (йөз дүрт) катнашучы кертелгән, 53 (илле өч) кеше гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан, бу 51 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 53 (илле өч) катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Клубная, Озерная урамнарында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Клубная, Озерная урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- тротуарларны төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту буенча эшләр.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авыл җирлеге, Зур Кызыл урамы, 113 А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ф. Салихзянов